## *Табигать почмагы*

# Канатлы дусларыбыз

Кошлар —безнең нәни ярдәмчеләребез, дусларыбыз һәм юлдашларыбыз. Кайбер чакны алар безнең өчен генә җырлыйлар да сыман. Эш җырда гына да, аларның матурлыгында гына да түгел, ә бәлки аларның табигатькә һәм кешеләргә ярдәмендә.

Мәсәлән, кечкенә генә чебенче көн саен 400 дән артык төрле зарарлы бөҗәкләрне, чебеннәрне юк итә. Аңа бу исемне шуңа биргәннәрдер, мөгаен.

Ару-талуны белмәс чеберчек бакчаларга бик еш очып килә. Ул үзенең рационына чебен, черки, чикерткә, озынборын, коңгыз һәм аларның кортларын кертә һәм көненә үз гәүдәсеннән күпкә авыр бөҗәкләрне ашый ала. Һәркемгә мәгълүм: яз хәбәрчесе—тургай ужым ябалакбашы, ташбака һәм башка авыл хуҗалыгы корткычларын юк итүче.

Зур песнәк аеруча игътибарга лаек. Ул 7 дән алып 17 гә кадәр бала чыгара. Һәм аларга ояда булган 20 көндә, 8 меңгә кадәр бөҗәк ташый. Ала тукранны тикмәгә генә «урман докторы» дип атамыйлар. Ул бер генә зарарланган агачны да үз ярдәменнән читтә калдырмый, каеры ашаучыларны, мыекбайларны, мөгез койрыкларны һәм аларның личинкаларын бетерә.

Әйе, кеше күп гасырлар буена кошларның зур файдасын күреп яшәде. Аларның табигатьтәге роле бүген дә элеккечә үк кала. Чөнки аларның үсемлек корткычлары белән көрәштәге ярдәме әйтеп бетергесез зур. Элек киң күләмдә кулланылган агу химикатларның тере организм өчен куркынычлы булуын бүген яхшы беләбез. Кара каргалар яз көннәрендә ужым басуларына зыян китерәләр. Әмма алар бер үк вакытта май коңгызы һәм башка корткыч бөҗәкләрне дә күпләп юк итәләр. Әгәр иген корткычлары күпләп үрчесә, ужым язмышын хәл итүе читенләшер иде.

Кошлар —безнең канатлы дусларыбыз.Ләкин аларга кышын бик авырга туры килә. Кошларга салкын кыш һәм азык җитешмәүне җиңеп чыгуда кеше ярдәмгә килә ала.

Кошларга җим бирү табигатьне саклау җәмгыяте членнары һәм яшь натуралистларның игътибар үзәгендә булырга тиеш. Мәктәп балалары, кошларны яратучы һәркем бу эштә ярдәмгә килә ала. Фанер яки такта кисәгеннән өстәлчек ясап, тәрәзә каршына, я булмаса агач ботагына беркетеп куюы, шунда кошларга җим салуы авыр эш түгел.

Безнең бакчаларыбызда, урманнарда, паркларда сыерчык оялары һәм җим салу урыннары күбрәк булсын. Ә кошлар күрсәткән изгелек өчен кешегә бурычлы булып калмаслар— алар бер гектар урман-бакчаны гына, бер тонна ашлыкны гына түгел, меңләгән гектар яшеллекне һәм игенне саклап калырлар.

**О. ЛЯПИН.**

**Шулай бер чакны...**

# Ышансаң ышан, ышанмасаң...

Менә анысы һәркемнең үз эше инде. Әмма хәзер, күзгә күренеп маҗаралар пәйда булганда, «бара-башкалар» һәм НЛОлар заманында һичкемне һичнәрсә белән гаҗәпләндерермен димә. Бары үзе шундый маҗарага тарган кеше генә беравык төштәге сыман хис итә үзен. Алия белән дә шундый хәл булды.

28 март көнне кичке 9 ларда Колбай Мораса авылында була бу хәл. Алия Садыйкованы авыл читендәге йортта торучы укучы кыз Зөлфирә Мәхмүтова туктата.

—Апа, әнә анда, күктә ниндидер ике тәлинкә сыман әйбер бар,—ди ул.

Чыннан да, И. Сафиуллиннар йорты янында, трансформатор турысында биектә ай зурлыгы чамасы 2 шар күренә. Зәңгәрсу кызгылт төстә була ул. Алия өенә дип шул якка юнәлә. Килеп җитәрәк, шарның берсе юк була. Үтеп киткәч борылып карасa..! Шарның берсе аның артыннан хәрәкәтләнә. Алия адымын тизләтә, теге шар да тизрәк хәрәкәт итә сыман. Кызга курку иңә. Элекке почта бинасы янына җитәрәк күтәрелеп караса, баш очында 3—4 метрлар биеклектә генә шар! Зәңгәрле-кызыллы нурлардан торган шарның ике ягында ак канат сыман түгәрәк чыккан. Алия өнe алынып, бар көченә йөгерергә керешә. Аяклары тыңламый, йөрәге куркып тибә башлый. Ниһаять, бер йортның капкасына килеп җитә, өйгә керә. Өй эчендәгеләр тизрәк урамга ташланалар, әмма берниди шар да күренми...

Нәрсә бу? Куззалдау, хыял көче дияр идең, шул көнне аны авылда күрүчеләр шактый була. Төнге сәгать 12 ләрдә аны авылның икенче башында да күрәләр. Алия үзе хәзер бу хәлләрне куркыныч төш сыман гына сөйли. Куркыныч —чөнки билгесез.

Авыл кешеләре да кайсы елмаеп, кайсы шаккатып тел шомарта, ә үзләре тагы ниндидер могҗиза көтә. Ни булыр? Кайчан? Кем белән? Кемнәр анда? Ни өчен килгәннәр? Бихисап сорау, бихисап билгесезлек. Аларга җавапны вакыт кына бирә ала.

**С. НУРУЛЛИНА.**

**Бер мәктәп хәбәрләре**

### Эшләп табалар

Безнең мәктәптә I—II класс укучылары күптән түгел ярминкә уздырдылар. Биредә һәр класс үз хезмәтен күрсәтте. Алар пешергән тортлар, пироглар, печеньелар белән өстәлләр тулган иде. Ярминкәгә килгән һәркем берсеннән-берсе матур итеп бәйләнгән, теккән киемнәрне алып калырга тырышты. Алар өчен төрле сурәтләр төшерелгән такталар, көрәкләр дә бар иде. Бу көнне һәр класс 20—27 шәр сумга кадәр акча җыйды. Җыелган акчаларны алар үз кирәкләренә тотачаклар.

### Очрашу кичәсе

Шул көннәрдә Кизләү урта мәктәбендә мәктәпне тәмамлап хәзер төрле өлкәләрдә эшләүчеләр, төрле уку йортларында белем алучылар белән очрашу кичәсе булды. Очрашуга килүчеләрнең мәктәпне тәмамлаганнан соңгы тормышы турында сөйләвен укучылар бик кызыксынып тыңладылар.

Кичәнең икенче өлешен уеннар, ярышлар, җырбию дәвам итте. Соңыннан мәктәп ашханәсендә укучылар хәзерләгән сыйдан авыз иттек.

**И. ХӘЙРЕТДИНОВА,**
мәктәп китапханәчесе.

# Авылыбыз яшәрә

Кондырчаның зур, тулы сулы, киң булып аккан чаклары булды. Янында гына, авылга үзенә бер төрле ямь биреп, җил тегермәне тора иде. Ә кичләрен халык җыелышып, уенга чыга иде. Тик соңгы елларда авыл бушап калды. Яшьләр күзгә күренеп кимеде. Колхозлар аерылып «Кондырча» махсус хуҗалыгы исемен алгач кына күп нәрсә үзгәреп куйгандай булды. Бәйрәмнәрне дә бергәләп уздыра башладык. Менә шулай 8 нче март бәйрәме дә авыл халкы өчен тере, шатлыклы көнгә әйләнде. Иртән иртүк хатын-кызларның яшькарты матур киенеп культура йортына агылды. Ә анда аларны күңелле музыка тавышы каршы алды. Соңыннан тантаналы төстә чәчәкләр бүләк ителде. Аннан соң аларны торт белән коймак пешереп чәй эчерделәр. Бәйрәм төнгә кадәр дәвам итте, барыбызның да күңелен ачты.

Бәйрәмнәр шулай узса, көннәр күңелле үтсә бәлки авыл яңадан яшәрер, Кондырча тагын зур сулы булып шаулап ага башлар иде.

**С. ХӨСӘЕНОВА.**
пенсионер.

# Архивлар һәм хәбәрдарлык

...КПССның Мари өлкә комитетының партия политмәгарифе йортында ачылган күргәзмә шулай дип атала. Анда КПСС өлкә комитеты партия архивыннан, МАССР Министрлар Советы каршындагы Үзәк дәүләт архивыннан һәм өлкә комсомол оешмасы тарихы музее фондларыннан документлар тәкъдим ителгән. Элек «җиде йозак» астында яткан документлар белән бүген һәркем таныша, теләсә аны өйрәнә ала. Бу материаллар авыр ачлык еллары, репрессияләнгән кешеләр турындагы хакыйкатьне ачалар.

Күргәзмәгә килүчеләрнең кайберләре еш кына биредә үзләренең якыннары, аларның язмышы турында элек белмәгән хәбәрләргә юлыгалар.

«Реабилитация»— республикада чыга торган



«Марийская правда» газетасында шундый рубрика астында сталинизм корбаннары исемлеге дөнья күрә.

Рәсемдә: (аста) МАССР Үзәк дәүләт архивының информация бүлеге мөдире В. П. Шомина (уңнан икенче) күргәзмәгә килүчеләргә экспонатлар турында сөйли.



**ТӨРЛЕСЕННӘН**

Пушкин 20 яшендә «Руслан һәм Людмила» поэмасын, Лермонтов «Вадим» повестен яза. Гоголь үзенең «Диканька янындагы хуторда кичләр» дигән әсәрен 22 дә, ә Рахманинов «Алеко» операсын 19 яшендә иҗат итә.

«Тын Дон»ның беренче китабын Михаил Шолохов 23 яшендә язып бетерә. Табигать фәннәре буенча беренче гыйльми дәрәҗәсен алганда Пьер Кюрига бары 16 яшь була.

Дөньяның иң зур математиклары йөз ел буена баш ватып та чишә алмаган Лиувилл мәсьәләсен грузин студенты Теймураз Вепхвадзе 21 яшендә чишә.

* * *

Иллинойс (АКШ) университеты биохимиклары нефть белән тукланучы бактерияләр булуын ачыклаган.


**БЕЛДЕРҮЛӘР**

**«Агропромхимия» производство берләшмәсенә КамАЗ, ЗИЛ һәм Урал автомашиналарында эшләү өчен шоферлар, Т-150, МТЗ-80, ДТ-75 тракторчылары, токарь эретеп-ябыштыручы, йөкчеләр кирәк. Хезмәткә түләү эш башыннан-премиаль.**

**Белешмәләр өчен адрес: Норлат шәһәре, Куйбышев урамы, 102, кадрлар бүлеге. Телефон: 2—22—08.**

* * *

**Димитровград юллар дистанциясенә юл монтеры (хезмәткә түләү айга 250—300), мастер-бригадир (хезмәт хакы 300—400 сум), өлкән юл мастеры (400—450 сум), участок начальнигы (450—500 сум) кирәк. Моннан тыш озак еллар эшләгән өчен, предприятиенең еллык эш йомгаклары буенча 13 нче хезмәт хакы түләнә, елына бер тапкыр түләүсез йөрү өчен билет, арзанайтылган бәяләрдә ягулык материалы бирелә. Даими эшкә кабул ителгәннәр махсус кием-салым, түләүсез ашау-эчү белән тәэмин ителәләр.**

**Малыкла, Якушка, Обамза, Әмировка, Кармала, Погрузная, Чаллы, Сосна, 989 километрдагы станцияләрдә квартиралар бар.**

**Белешмәләр белән Малыкла, Якушка, Чаллы, Шентала, Погрузная, Кармала юл мастерларына яки Димитровград шәһәре, Вокзальная урамы, 46 йорт, юллар дистанциясе кадрлар бүлегенә мөрәҗәгать итәргә.**

**АДМИНИСТРАЦИЯ.**



**РЕДАКТОР Ә. У. АБДУЛЛИН.**

**«Дуслык» газетасы атнаның сишәмбе, пәнҗешәмбе, шимбә көннәрендә чыга һәм рус, чуваш телләренә тәрҗемә ителә.**

**РЕДАКЦИЯНЕҢ АДРЕСЫ: 423000. Норлат шәһәре, К. Маркс урамы, 19.**
**ТЕЛЕФОННАР: редактор—2—12—14, 2—22—81, редактор урынбасары һәм җаваплы секретарь—2—10—44, рус теленә тәрҗемә буенча редактор урынбасары—2—14—16, чуваш теленә тәрҗемә буенча редактор урынбасары—2—15—63, агропромышленность бүлеге—2—22—51, хатлар бүлеге һәм бухгалтерия—2—18—67.**

**Газетаны Фидания Хәйретдинова җыйды. Рима Ганеева верстка ясады. Клара Бобкова басты. Корректор—Зөлфия Вәлиева.**

**Нәшрият, полиграфия һәм китап сәүдәсе буенча ТАССР Дәүләт комитетының Октябрьның 50 еллыгы исемендәге Норлат-Октябрь типографиясе.**
**Күләме—1 басма табак. Заказ 40. Тираж 3.890.**